КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 июль г.Казань № 779

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1110 нчы; 2021 ел, 2 апрель, 212 нче; 2021 ел, 20 июль, 605 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 10 июнь, 543 нче; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплексны үзәкләрендә база окладына (хезмәт хакы ставкасы) өчен социаль хезмәткәрләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдаланучылар санының тәкъдим ителә торган нормативы түбәндәгечә тәшкил итә:

15 кеше – гражданның озак вакытлы карау системасы кысаларында карауга ихтыяҗы булмаганда; граждан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак

вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарында каралган озак вакытлы карау буенча социаль пакет (алга таба – социаль пакет) бирүдән баш тартканда; гражданга социаль пакетка керми торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль хезмәтләр күрсәткәндә;

6 кеше – гражданга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карары нигезендә билгеләнгән карауга беренче мохтаҗлык дәрәҗәсе (алга таба – карауга мохтаҗлык дәрәҗәсе) буенча социаль пакет биргәндә;

3 кеше – гражданга карауга икенче мохтаҗлык дәрәҗәсе буенча социаль пакет биргәндә;

2 кеше – гражданга карауга өченче мохтаҗлык дәрәҗәсе буенча социаль пакет биргәндә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче; 2016 ел, 18 июнь, 413 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 705 нче; 2019 ел, 8 февраль, 82 нче; 2020 ел, 10 февраль, 84 нче; 2021 ел, 8 июнь, 441 нче; 2022 ел, 19 февраль, 138 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1324 нче; 2023 ел, 16 март, 260 нчы; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.5 пунктның 3.5.1 пунктчасында «чит кеше» сүзен төшереп калдырырга;

5.1 пунктның 5.1.5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

6.3 пунктның 6.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3.1. Социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү өчен кирәкле һөнәри эшчәнлек төрләре буенча персонал саны булырга тиеш.

Бер социаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган социаль хезмәтләрдән файдаланучылар санының тәкъдим ителә торган нормативы түбәндәгечә тәшкил итә:

15 кеше – гражданның озак вакытлы карау системасы кысаларында карауга ихтыяҗы булмаганда; граждан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарында каралган озак вакытлы карау буенча социаль пакет (алга таба – социаль пакет) бирүдән баш тартканда; гражданга социаль пакетка керми торган социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында билгеләнгән социаль хезмәтләр күрсәткәндә;

6 кеше – гражданга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы

карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карары нигезендә билгеләнгән карауга беренче мохтаҗлык дәрәҗәсе (алга таба – карауга мохтаҗлык дәрәҗәсе) буенча социаль пакет биргәндә;

3 кеше – гражданга карауга икенче мохтаҗлык дәрәҗәсе буенча социаль пакет биргәндә;

2 кеше – гражданга карауга өченче мохтаҗлык дәрәҗәсе буенча социаль пакет биргәндә.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Карауга мохтаҗлык булмаганда карау буенча социаль хезмәтләр (озак вакытлы карауның социаль пакеты) түбәндәге категориядәге гражданнарга, әлеге хезмәтләр 2023 елның 1 июненә кадәр күрсәтелгән очракта, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күрсәтелә:

Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

Бөек Ватан сугышында катнашучылар;

һава һөҗүменә каршы оборона, һава һөҗүменә каршы җирле оборона объектларында, гамәлдәге фронтларның тыл чикләре буенда оборона корылмалары, хәрби диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар, гамәлдәге флотларның операция зоналары төзелешендә, фронт янындагы тимер һәм автомобиль юллары участокларында эшләгән затлар;

Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында тоткарланган транспорт флоты суднолары экипажларының әгъзалары;

«Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар;

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән затлар (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә);

Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар.»;

«**» астөшермәсендә «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1993 елның 6 февралендәге 105 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 14 сентябрендәге 629н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның «*» астөшермәсендә «чит кеше» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Бу карарның 1 пункты, 2 пунктындагы дүртенче – унынчы абзацларының гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин